Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 8 (21)

22 март 2012 ел

## • Ике авыз сүз

19 март көнне ректоратның чираттагы утырышы үтте. Беренче булып икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор М.Сафиуллин КФУ делегациясенең Сингапурга булган визиты турында сөйләде. Дөнья күләмендә танылган Сингапур Татарстан белән күптән хезмәттәшлек итә. Алга таба Казан федераль университеты белән дә тыгыз элемтәләр урнаштырылачак. Делегация Сингапурның Милли, Наньян технология университетлары, Дәүләт хезмәткәрләре колледжы һәм Ли Куан Ю исемендәге дәүләт сәясәте мәктәбендә булды. Сингапурның Укытучылар ассоциациясе белән хезмәттәшлек турындагы Меморандумга кул куелды.

Алга таба Н.И.Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институтының үсеш программасы турында директор В.Чугунов чыгыш ясады. Ректор Илшат Гафуров презентациягә бәйле тәкъдимнәрен белдерде. Университет һәм институт арасындагы бәйләнешне күрсәтергә кушты, эшләнгән эшкә нәтиҗә ясау гына түгел, ә киләчәккә планнарны да билгеләргә тиешлекне ассызыклады.

Ректор Илшат Гафуров РФның Мәгариф һәм фән министрлыгына кертеләчәк яңа үзгәрешләр турында сөйләде. Тышкы элемтәләр департаменты директоры А.Крылов 2012 елга ТР Хөкүмәте гранты «Алгарыш» конкурсының шартлары белән таныштырды. Быелгы таләпләр буенча һәр университет хезмәткәрләрен стажировкага үзе җибәрәчәк. Ректоратта катнашучылар, үз вузына кире кайтып, аның үсешенә ярдәм итәрдәй белгечләрне җибәрергә кирәк, дигән нәтиҗәгә килде.

Фәнни эшчәнлек буенча проректор Д.Нургалиев Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты базасында ачылачак яңа фаза анализы, компьютер томографиясе, Җир өстен дистанцион тикшерү лабораторияләре турында мәгълүмат җиткерде.

Хезмәт куркынычсызлыгын тәэмин итү бүлеге җитәкчесе Т.Зимина 16 март көнне А.М.Бутлеров исемендәге Химия институтында булган гадәттән тыш хәл турында искә төшерде. Бром түгелү аркасында, бөтен институтны эвакуацияләргә туры килә. Илшат Гафуров биология һәм туфракны өйрәнү факультеты, Физика һәм Химия институтларында куркынычсызлыкны кайгырту буенча боерык әзерләргә кушты. Аның өчен бүлек җитәкчеләре җаваплы итеп билгеләнде.

• • • •

19 март көнне журналистика һәм социология факультетында башланып киткән «Медиаполигон» проекты «Русский репортёр» журналының яңа проекты булып тора. Әлеге журнал яшь журналистларны хәзерге мәгълүмати мәйданда җайлашырга, массакүләм мәгълүмат чараларында эшләргә әзерли. Ә катнашучылар «Медиаполигон»да алган белем һәм күнекмәләрне «Шәһәр-24» проектында сынап караячак. Ул чараның соңгы көнендә старт алып, тәүлек буе шәһәрдә барган вакыйгаларны онлайн режимда тәкъдим итәчәк. Кереш мастер-классны «Русский репортёр» журналының «Фән» бүлеге мөхәррире Григорий Тарасевич уздырды. Кызыклы һәм үзенчәлекле чыгышта ул яхшы журналистка хас булырга тиешле 35 сыйфатны санап үтте.

• • • •

Мартның беренче яртысы Алабуга филиалы спортчыларына зур җиңүләр алып килде. Владимир өлкәсенең Суздаль шәһәрендә юниорлар арасында пауэрлифтинг буенча узган Чемпионатта студентлар югары күрсәткечләргә иреште. Ярыш нәтиҗәләре буенча Анастасия Куликова һәм Михаил Волков Россиянең җыелма командасы составында бу елның 20-26 маенда Чехиядә узачак Дөнья беренчелегендә катнашачак.

• • • •

Күптән түгел Филология һәм сәнгать институтының концерт залында композитор Рөстәм Яхинга багышланган кичә узды. Үзенең мәгънә тирәнлеге һәм жанр төрлелеге ягыннан аерылып торган программаны ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе Әнисә Абдуллина әзерләгән иде. Рөстәм Яхин әсәрләрен Ә.Абдуллина, Бөтенроссия һәм төбәкара конкурслар лауреаты Ф.Мөхтәрова, ТРның халык артисты М.Галиев, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе М.Габитов, бүлекне тәмамлаган һәм бүген биредә белем алучы студентлар башкарды. Кичәнең әдәби бизәлешен әзерләгән ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе Л.Асадуллина үзе алып та барды.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Алия Галимуллина фотосы

# Нәүрүз мөбарәкбад!

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Нәүрүз бәйрәме төрки халыкларда яз башында, табигать уянган вакытта үткәрелә. Нәүрүз фарсыча «яңа көн» дигәнне аңлата. Урта Азия, Иран, Әфганстан, Үзбәкстан, Казакъстан һәм кайбер башка илләрдә бик борынгыдан Яңа елны каршылау бәйрәме буларак үткәрелә. Нәүрүз көн белән төн тигезләшкән чорга – 21-22 мартка туры килә.

Бу көннәрдә бөтен төрки дөньяда гына түгел, Татарстанның башкаласы Казанда да Нәүрүз бәйрәме чаралары гөрли. Кичә, ягъни 21 март көнне безнең Казан федераль университетында да Нәүрүзгә багышланган зур чара узды. Биредә Филология һәм сәнгать институты, Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты студентлары катнашты. Ираннан килгән «Гөлбанг» (иранчадан - «гөлләр тавышы») ансамбле әлеге чараның йөзек кашы булды. ТР Министрлар кабинеты, Мәдәният министрлыгы вәкилләре янәшәсендә Иранның Татарстандагы Баш илчесе Рәсүл әфәнде Багернежад Шаян да бар иде.

Безнең борынгы бабаларыбыз, төркиләр буларак, Нәүрүзгә зур әһәмият биргән. Урта Идел буенда яшәгән татарларның яңа елны март аенда башлап җибәрүе мәгълүм. Әле XIX гасырда да Нәүрүз көннәрендә (ул атна-ун көнгә сузылган), йорттан-йортка кереп, «нәүрүз әйтеп йөрү» гадәте булган. Моны укучы балалар - шәкертләр башкарган. Нәүрүз такмагын әйтеп, хуҗаларга бәхет, уңышлар теләп йөргәннәр. Бу инде алар өчен үзенә күрә бер күңел ачу була: салкын кышлар бетеп, яз килүгә шатлану, авыл халкының күңелен күтәрү. Нәүрүз әйтүләр беркайчан да бушка булмаган. Алар күчтәнәч, акча таләп иткәннәр. Нәүрүз такмаклары төрлелеге белән аерылып торган: «Ач ишегең, керәбез, Нәүрүз әйтә киләбез, хәер-дога кылабыз, аш-су көтеп торабыз, Нәүрүз мөбарәкбад!»

Еш кына шәкертләр, үз авыл халкына җайлаштырып, аларны үзләре үк уйлап чыгарган: «Нәүрүз килә яшәреп, яшәреп тә теш ярып. Сөләйман абзый, көтәмсең, табак-савыт бирәмсең? Нәүрүзгә табак кирәк, табакка кабак кирәк, май, күкәй, күмәч кирәк!»

Нәүрүз көнне кешеләр күңелендә гел игелек кенә булырга тиеш. Ул изгелек булып аның үзенә үк кайтачак. Яңа елны ничек каршыласаң, шулай үтәр дип уйлау күбрәк шатлану, башкаларга куаныч өләшү теләгеннән уяткан. Кеше үз өстендәге бурычлардан да котылырга тырышкан. Нәүрүз буласы төндә иртәнгә кадәр күмәк җыелган ярмалар һ.б. ризыклардан ботка пешергәннәр.

Бу көнне хуҗабикәләр табынга фарсыча «с» хәрефеннән башланган җиде төрле ризык куярга тиеш булган (су, сөт, сүмәләк - Нәүрүздә пешерелгән ботка (кесәл), сарымсак...). Иртән торып, урамга чыгуга, беренче очраткан кешенең ир-атмы, хатын-кызмы икәне дә бик әһәмияткә ия булган (ир-ат очраса, елың уңышлы була дип ышанганнар).

Менә шулай, дуслар, 21 март - ул безнең тагын бер матур, мәгънәле бәйрәмебез.

## • Эшлекле сөйләшү

# «Дөньяны үзгәртүне бала тәрбияләүдән башларга кирәк»

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Януш Корчак шулай дигән. 19 март көнне Педагогика һәм психология институтында авыр хәлдә калган балаларны тәрбияләү мәсьәләләренә багышланган төбәгара семинарда моның шулай булуына инанырга мөмкин иде. Ул танылган тәрбияче Януш Корчак елына һәм Казан университетында педагогик белем бирүнең 200 еллыгына нисбәтле узды.

Чарада Татарстанның барлык төбәкләреннән кискен хәлдәге балаларны тәрбияләү белән шөгыльләнүчеләр, тернәкләндерү үзәкләренең җитәкчеләре, педагоглар һәм студентлар катнашты.

**Ахыры 2нче биттә.**



● Халыкара багланышлар

# Тырышсак - булыр!

Сиринә ТРОФИМОВА,
хәбәрче

Казан федераль университеты ректоры Илшат Гафуров җитәкчелегендәге делегациянең Сингапурга визиты тәмамланды. Визит кысаларында Сингапурның фәнни һәм мәгариф үзәкләре белән танышу, чит ил коллегаларыннан квалификацияне арттыру тәҗрибәсен үзләштерү һ.б. тормышка ашырылды. Делегация составында катнашкан Педагогика һәм психология институты директоры Айдар Миннемансур улы КӘЛИМУЛЛИНга берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек.



***– Айдар Миннемансурович, Сингапур дәүләте Сездә нинди тәэсирләр калдырды?***

– Искиткеч тәэсирләр белән кайттык. Сингапур – Төньяктан Малайзия дәүләте белән чикләнгән, 632 км$^2$ күләмле, 58 зур булмаган утраудан торган, республикада бердәнбер Сингапур исемле шәһәре булган ил. Халкы шул дәрәҗәдә эшчән, тырыш. Балалар һәм яшьләр гел уку белән мәшгуль. Безне таң калдырганы – шәһәрдәге яшеллек, матурлык, чисталык һәм тәртип. Ничә көн яшәп, бер полиция хезмәткәре күрмәдем. Урамда тәмәке тарткан, чүп ташлаган кешеләргә зур күләмдә штраф каралган. Дәүләт территориясенә әфьюн кертүчегә үлем җәзасы бирелә. Шулай ук бу илгә сагыз кертүдә катгый тыела, хәтта бер елга төрмәгә утыртырга мөмкиннәр.

***– Сингапурда төрле милләт вәкилләре яши, алар үзара ничек аралашалар һәм телләргә карата дәүләтнең мөнәсәбәте нинди?***

– Аларның дәүләт теле – инглиз, кытай һәм малайзия телләре. Без балалар бакчасында, мәктәпләрдә булдык. Һәр мәктәптә инглиз теле мәҗбүри укытыла, югары уку йортларында инглизчә белем алалар, студентлар дөньяның иң алдынгы уку йортларында стажировка үтә. Төп аралашу теле – инглиз теле. 3 яшьлек бала бакчага килүгә, аны инглизчә өйрәтә һәм шул телдә аралаша башлыйлар. Тик нинди генә милләт баласы булмасын – кытаймы, австриялеме, индусмы, тамильмы, малайзиялеме... – ана теле укытучылары аларга үз туган телләрен дә укыта. Балалар бик тәрбияле. Бер гаиләдә кунакта булырга туры килде – әтиләре австрияле, әниләре рус (Казаннан), балалары инглиз, рус, немец телендә рәхәтләнеп сөйләшә. Халык үзара дус яши. Телләргә бәйле проблемалары юк аларның.

***– Айдар әфәнде, Сез Сингапурның квалификацияне арттыру буенча эшләүче укытучылар профсоюзы белән очрашуда да катнаштыгыз һәм директор Майк Тируман белән киләчәктә хезмәттәшлек итү турындагы килешүгә кул куйдыгыз. Хәзерге көндә безнең Татарстан укытучыларының квалификациясен күтәрү өлкәсендә проблемалар бар. Сингапурдагы килешү бездәге бу проблеманы чишәргә ярдәм итәрме?***

– Әйе, бу мәсьәләне яхшы беләм мин. Кемнең теләге бар, беләме ул бу өлкәне, белмиме – укытучыларның квалификациясен күтәрү юнәлешендә эшләргә азаплана башлады. Безнең институт каршында Рәис Шәйхелисламов җитәкчелегендә эшли торган Мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге тарафыннан тәкъдим ителгән концепция нигезендә эшчәнлекне ныклап башларга җыенабыз. Апрель аенда Казанда, бу өлкәдә тәҗрибәләр белән уртаклашу һәм ярдәм итү максаты белән, Сингапурдан квалификацияне арттыру буенча эшли торган укытучылар профсоюзы вәкилләрен каршы алачакбыз. Безнең Татарстаныбыз төшеп калганнардан түгел. Тырышсак, барысын да булдырырбыз.

***– Сезгә укучыларыбыз исеменнән дә уңышлар телибез!***

● Алар бездә укыган

# Зыялы зат

Динара ӘХМӘТОВА,
хәбәрче

Үзләренең гыйльми эшчәнлеге белән фәннең дөньякүләм үсешенә зур өлеш керткән һәм югары квалификацияле белгечләр әзерләүдә күп көч сарыф иткән Казан университеты галимнәре янәшәсендә физика-математика фәннәре докторы, профессор Гомәр Тумашев та лаеклы урын алып тора. Аның күпсанлы шәкертләре арасында күренекле белгеч һәм галимнәр дә шактый.



■ *Гомәр Тумашев (беренче рәттә уртада) теоретик механика кафедрасы хезмәткәрләре арасында*

Гомәр ага 1910 елның 21 ноябрендә Чистай шәһәрендә туа. Әтисе Гали Тумашев Гомәр дөньяга килгән елны 43 яшендә вафат була. Әнисе Әсма ханым баш киемнәре тегү белән көн итә. Әнисе янында үскән Гомәрне 1922 елдан 1927 елга кадәр абыйсы Исмәгыйль тәрбияли.

1927 елны Чистайда җидееллык мәктәпне тәмамлаган егет Казан шәһәрендәге индустриаль политехникумның күнчеләр бүлегенә укырга керә. Техникумны тәмамлагач, «Спартак» аяк киемнәре комбинатында смена мастеры булып эшли. 1932 елны Казан университетының физика бүлегенә укырга керә. Үз теләге белән Казан авиация институтына күчә һәм I дәрәҗәле инженер-механик дипломы ала. Институтны тәмамлаганнан соң, аэродинамика кафедрасында аспирантурага кала. Нәтиҗәдә Гомәр Гали улы аэрогидродинамика фәненең үсеш юнәлешләрен һәм перспективаларын алдан күрә белүче, гаять киң эрудицияле күренекле галим дәрәҗәсенә ирешә.

1941 елның июнендә, сугыш башлану белән, югары уку йортларында да тормыш кискен үзгәрә. Бу чорда да галим зур педагогик һәм гыйльми эшчәнлек алып бара, сугышның иң кискен вакытларында студентлар белән бергә Идел буе оборона чиген төзүдә катнаша. Казанда эвакуациядә булган Үзәк аэрогидродинамика институты филиалының аэродинамика кафедрасына өлкән инженер буларак кабул ителә. Очкыч аэродинамикасы буенча хөкүмәт эшен башкара.

1944 елда гыйльми җитәкчесе Г.Каменков киңәше буенча, Казан университеты ректоры исеменә, үзен механика кафедрасы доценты итеп кабул итүне үтенеп, гариза яза. Нәкъ шул елдан Гомәр Гали улының биографиясе, иҗаты Казан университеты һәм механика факультеты белән бәйләнә. Тиздән Тумашев бу кафедраның мөдире була һәм 1954 елга кадәр җитәкчелек итә. Механика кафедрасы белән җитәкчелек итә башлау чорында, әлбәттә, кафедра тулы мәгънәсендә кафедра булмый. Бердәнбер доцент К.Галимов университетта бөтен механикага бәйле фәннәрне укыта. Г.Тумашев алдындагы иң катлаулы мәсьәләләрнең берсе университетта механика фәнен укытуны торгызу була. Ул гыйльми эшне оештырып җибәрә, яшь хезмәткәрләр чакыра. Аспирантурада яшь кадрлар әзерләүгә игътибарын арттыра. Гомәр Гали улы җитәкчелек иткән гидромеханика кафедрасы уку-укыту процессын оештыру һәм фәнни тикшеренүләрне үстерү, алга җибәрү буенча Казан университеты кафедралары арасында иң яхшыларның берсе була. Г.Тумашев тарафыннан барлыгы 8 фән докторы һәм 35 фән кандидаты әзерләнә. Бөек Ватан сугышында катнашучылар М.Нужин, Б.Филиппов, Р.Насыйров, В.Чугунов, М.Копырин һ.б. Г.Тумашевның беренче фән кандидатлары була.

1951 елны ТР җитәкчелеге Казан галимнәренә кара алтын чыгару сәнәгатенә ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итә. Шул ук елны Казан университетында җир асты гидромеханикасы буенча Г.Салихов һәм Г.Тумашев җитәкчелегендә фәнни семинар эшли башлый. Казан университетының һәм СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы каршындагы Казан физика-техника институты аспирантлары, галимнәре биредә актив катнашалар.

1954 елда механика кафедрасы теоретик механика һәм аэрогидромеханика кафедраларына бүленә. Беренчесен – М.Нужин, икенчесен 1980 елга кадәр Г.Тумашев җитәкли. Механика өлкәсендә бик зур ачышлар ясаган галим, 70 яше тулгач, кафедрада профессор-консультант булып кала.

Әдәплелек, тумыштан килгән зыялылык, ярдәмчеллек сыйфатлары белән үзенә тартып торган олуг шәхес һәм галим укучылары, хезмәттәшләре хәтерендә һәрвакыт сакланыр.

*«Мәшһүр татар галимнәре» хезмәте файдаланылды.*

● Эшлекле сөйләшү

# «Дөньяны үзгәртүне бала тәрбияләүдән башларга кирәк»

**Башы 1нче биттә.**

«Баланы ничек яратырга соң? Эшне, беренче чиратта, аңа рөхсәт ителгән гамәлләрнең чикләрен күрсәтә белүдән башларга кирәк!» – гомуми һәм социаль педагогика кафедрасы мөдире Роза Вәлиева пленар утырышны шундый сүзләр белән башлап җибәрде. Чыннан да, гомер-гомергә укытучылар, тәрбиячеләр өстенә гаять зур җаваплылык салынган: баланы дөрес итеп тәрбияләү. Һәр баланың уникаль, башкаларга охшамаган булуын таный белү мәсьәләсенә җитди карарга кирәк. Баланың үсешен тоткарлый торган факторларны да истән чыгармау беренче планда булырга тиеш.

Семинар барышында, Мәскәү кунагы, профессор Ирина Демакова бу сорауга киңрәк тукталды. Уйлап карасаң, акыл ягыннан сәламәт булмаган, үсешендә тоткарлыклар килеп чыккан балалар бүген мәктәпләрдә шактый. Нидән килеп чыга соң мондый кимчелекләр? Беренчедән, баланың үсешен тоткарлаучы күренеш – ул курку. Алдагысы – үзеңне гаепле тою. Һәм инде өченче фактор – ул оятка калу. Әйе, әйе, нәкъ менә оялу да балага тискәре йогынты ясарга бик мөмкин. Исегезгә төшерегез әле: мәктәптә укыганда, сезне яки башка сыйныфташыгызны берәр гаебе өчен бөтен сабакташлары арасында ачулану, аның өстенә, такта янына чыгарып, тагын бер кызарту, көндәлеккә кисәтү язу кебек күренешләр булгалый идеме? Педагогик яктан караганда, мондый алымнар иң начар нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Шуны да онытмаска кирәк: балачакта алган үпкә ул беркайчан да хәтердән чыкмый, йөрәкнең иң түренә үтеп керә. Ирина Демакова үзенең чыгышын: «Һәрбер бала үз хокукларын белергә тиеш!» – дигән сүзләр белән тәгәлләде.

Семинарның төп максаты Януш Корчакның идеяләрен яктырту иде. Хәтерләсәгез, 2012 ел ЮНЕСКО тарафыннан балалар язучысы, танылган табиб, педагог Януш Корчак елы дип игълан ителде.

Семинар «түгәрәк өстәл»ләр, кызыклы мастер-класслар белән дәвам итте. Ә ахырдан барлык катнашучыларга да «кыска вакытлы курсларда белем алды», дигән сертификатлар тапшырылды. Барлык катнашучылар да уңай эмоцияләр белән таралышты.

Миңа калса, мондый төр очрашулар бик кирәк. Бигрәк тә бүген – яңа буынны тәрбияләгәндә, җәмгыятебез тәҗрибәле белгечләр, балалар психологиясен аңлаучы педагогларга аеруча да мохтаҗ...

● Кечкенә галимнәр

# Бар иде бит яшь чаклар…

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Бүгенге кунагыбыз – танылган галим, Физика институтының фәнни-педагогик белем бирү бүлеге мөдире, педагогика фәннәре докторы, профессор, күп еллар җитәкче урыннарда эшләгән Васил Габдулла улы ГАЙФУЛЛИН. Студент елларындагы истәлекләрен ул безнең белән дә уртаклашты…

«Безнең чорда, бездән соңгы елларда да студентларга җәйге каникул вакытларында эш күп булды. I һәм II курсларны тәмамлагач, Казакъстанга чирәм җирләрне үзләштерергә җибәрделәр. Безнең эш көне – иртәнге сигездән кичке сигезгә кадәр. Көндезге ашка бер сәгать чамасы туктап алабыз. Анда климат – кискен континенталь. Көндез – утыз градус эсселек, хәтта аннан да арта, төннәрен суыта, сентябрь ахырларында су ката. Ә иң кызыгы шунда: август ахырында карбыз өлгерә. Казакъстанда аны күпләп үстерәләр. Карбызлары да уңа. Басуда тәгәрәшеп яткан 10-15 кг карбызларны күреп, хәйраннар каласың!



Минзәлә педучилищесы укучысы. 1954 ел

Карбыз өлгергәч, тормыш тагын да ямьләнеп китә. Яшь вакыттагы инстинктлар яңара. Басуга барып, карбыз урларга план корабыз. Башкортстаннан урып-җыюга килгән Тимербай машинасын биреп тора. Илгизәр, Абрек һәм мин, караңгы төшкәч, машинаны алып чыгып китәбез. Рульдә – Илгизәр. Карбыз басуын саклыйлар, этләре дә, мылтыклары да була, диләр. Басуга якынлашкач, машинаның утын сүндерәбез, утсыз гына, моторны да сүндереп, инерция белән генә басу эченә керәбез.

Машинада Илгизәр белән икәү калып, Абрекны разведкага җибәрәбез. Ярты сәгатьләп утырабыз – Абрек юк. Борчыла башладык: «Тоттылар микәнни?» Алай дисәң, тавыш-мазар да ишетелмәде. Нидер булмагае, карап килергә кирәк. Мин киттем. Абрек киткән якка үрмәләп барам. Абрек янына килеп чыктым. «Нәрсә булды?» – дип пышылдыйм. «Тавыш чыгарма», – дип, бармагын иреннәренә аркылы куйды, колакка авызын терәп пышылдады: «Күрәсеңме каравылчыны, безгә мылтыгын төбәгән. Тора башласаң, атарга мөмкин. Ятып кына тор». Карыйм, чыннан да, каравылчы икән шул. Чечен булырга тиеш. Фуражкасы кавказлыларча, аэродром кебек, мылтыгын безгә караткан, бер кулы курокта. Бетәбез икән, дим. Башка әллә нинди уйлар килә. Үземне үзем сүгеп ятам. Нигә кирәк инде бу эш?! Карбыз урлыйлар, имеш! Урларсың, менә хәзер атып җибәрсә. И, институтта сөйләрләр инде! Карбыз урларга барганнар икән, шунда каравылчы атып үтергән. Карбыз урлап йөрмәсәләр... һ.б., һ.б. Авылга да бик начар кайтып ишетелер инде... Да-а, матур тәмамлый алмадың тормышыңны...

Ятабыз җирдә Абрек белән. Мин килгәч тә, 10-15 минут яттык бугай. Уйлап куйдым: каравылчы бер дә селкенмичә, шул кадәр торырга мөмкинме? Каравылчы түгелдер бу. Каравылчы чечен формасына охшатып ясап куелган карачкы гынадыр бу. Шушы фикерне тикшереп карау нияте белән, шуышып киттем тегенең янына. Барсам, ни күрәм: бер мәһабәт көнбагыш үсеп утыра. Башы чечен фуражкасыннан бер дә ким түгел, сабаклары мылтык тоткан кебек тырпаеп тора. Абрекны чакырам: «Менә кемнән куркып ятасың син!» Илгизәрне дә чакырып, тиз генә берничә капчык карбызны машинага төядек тә кайтып киттек.

Егетләр карбызга ташланды. Карбызны ничек ашарга өйрәнгән малайлар. Телемне бик калын итмичә генә кисеп алалар, авыз аркылы бер яктан үткәреп җибәрәләр, карбыз төшләре икенче яктан шыбыр-шыбыр коелып кына тора.

Бераздан өч метрлы озын өстәлгә карбыз чүбе тау булып өелә. Өстәлнең ике башыннан ике кеше тотып, чүпне чыгарып түгәләр, йокларга яталар. Бераздан карбыз үзен сиздерә башлый. Бүлмәдәге 15 егет берничә тапкыр йомышларын үтәргә чыгып керә. Чыгып, ерак бармыйлар: тулай торак өйалдысының баскычыннан гына башкаралар йомышларын. Сентябрьдәге аяз төннәр, гадәттә, кыраулы була. Малайларның йомышларыннан соң баскыч төбе шома бозга әйләнә. Ул бозда иртән безгә эшкә әйтергә кергән Хәким ага таеп егыла. Аның беренче сүзләре безне уята: «Эй, ребята, ребята...»

***P.S.** 23 март көнне күренекле галимебез Васил Гайфуллинга 75 яшь тула. Ихлас күңелдән аны бу истәлекле юбилее белән тәбрик итәбез, саулык-сәламәтлек, имин тормыш телибез!*

● Сәяхәттән кайткач

# Истәлеккә калыр хатирәләр

**Зөһрә ӘХӘТОВА,**
Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты студенты

27 гыйнвар. Аэропорт. Бер төркем студентлар укытучылары белән бергә Мисыр башкаласы Каһирәгә юл тота. Дулкынландыргыч вакыйга. Күңелдә берничә хис бергә кушылган: шатлану, сагыну һәм шул ук вакытта курку. Кемдер үзенең күптәнге хыялының чынга ашуына ышана алмыйча, чын күңеленнән шатлана. Ә берсе якыннарын сагына да башлаган инде. Икенчесенең карашы тәрәзәгә төбәлгән, эченнән: «Шундый еракка очабыз бит!» – дип уйлый.

Ниһаять, барлык тикшерүләр үтелде, без – самолётта. Тәгәрмәчләр җирдән аерыла, тимер кошыбыз әкренләп күккә аша. Шушы мизгелдә һәр кешенең йөрәге: «Сау бул, Казан!» – диеп дәште.

Башкала безне йомшак кышкы җилләре белән каршы алды. Мисырлыларның кышы безнең көз башына охшаган. Һава температурасы да 18-19 градус, нәкъ кирәгенчә.

Икенче көнне урам буйлап йөрергә чыктык. Каһирә кешеләре безгә сәерсенеп карап китәләр иде. «Нинди ил туристлары икән?» – дип уйлаганнардыр. Урам кеше белән тулган. Машиналар бер дә тынмый, тызбыз йөриләр. Каһирәдә аларның бер үзенчәлеге бар: бертуктаусыз «бип-бип», итәләр. Шул рәвешле машина йөртүчеләр бер-берсен я сәламлиләр, я «юл бир әле», диләр икән. Беренче карашка Каһирә куркыта да. Аның урамнарына күнегергә кирәк. Машина юлларын чыга алсаң, үзеңне Сабан туйда җиңгән батыр сыман хис итәсең. Яңа җиргә бик тиз күнегеп булмый икән. Монда, гомумән, икенче төрле менталитет, җитмәсә, Җир шарының икенче кыйтгасында бит син! Гарәп теленә күнегү авыррак булды. Һәр кешенең үз сөйләшү рәвеше: кемдер тиз сөйләшә, кемдер – салмак, кемдер сүзнең ахыргы иҗеген әйтеп бетерми.

Каһирә нәкъ гарәп язучылары тасвирлап биргән шәһәр булып чыкты. Ул көчле, дәһшәтле, горур, зур биналарга бай, әмма шул ук вакытта тузанлы, ыгы-зыгылы. Икенче төрле әйтсәң, аны әлеге формула белән кыска гына аңлатып булыр иде: Мәскәү + Казан = Каһирә.

### Уку – энә белән кое казу

Безнең төп максат белем алу иде. Шушы уйлар белән өченче көнне үк Каһирә дәүләт университетына юл тоттык. Мөгаллимнәр безне ачык йөз, киң колач белән каршы алды. Шул сәбәпле, алар белән аралашып китү безгә җиңел булды. Фәннәрнең төрлелеге, укытучыларның җылы мөнәсәбәте моңсуланырга ирек бирмәде. Гарәп теле грамматикасы, Мисыр диалекты, гарәп әдәбияты, җыр дәресе – сизелмичә үтәләр иде.

### Сәяхәтләр... сәяхәтләр...

Укудан тыш, без төрле экскурсияләргә дә йөрдек. Шуларның иң зурысы Мисырның көньягында урнашкан Луксор шәһәренә бару булды. Каһирәгә караганда, биредә күпкә җылырак – нәкъ безнең җәй. Луксор, башкала сыман ук, Нил елгасы белән ике өлешкә аерылган. Беренчесе – Көнчыгыш яр, икенчесе – Көнбатыш яр. Көнчыгыш ярны икенче төрле «Исәннәр дөньясы», дип йөриләр, чөнки әлеге ярда һәр иртәдә кояш калка, яңа тормыш башлана. Ә Көнбатыш ярны «Үлеләр дөньясы», диләр.



Ботаника бакчасында. Каһирә.

Биредә кояш бата, димәк, тормыш та бетә.

Беренче көнне «Исәннәр дөньясы»на бардык. Үзенең биек колонналары белән мәшһүр булган Карнаг сарае, чынлап та, миллион туристны үзенә җәлеп итәрлек тарихи бина. Шәһәр уртасында урнашкан Луксор сараен аның игезәге диеп атар идем. Элек шушы ике сарайны озын юл тоташтырган. Әмма вакытлар үткән саен, ул юкка чыккан.

Хатшепсут патшабикә сарае үзенең архитектурасы белән башкалардан аерылып тора. Зур заллар баскыч сыман берсе өстендә берсе урнашкан.

Икенче көнне Көнбатыш ярга – фараон төрбәләренә юл тоттык. Моның хәтле гүзәллекне күреп шаккатасың. Ничек шушы таулар, авыр-авыр ташлар җимерелми икән?! Бигрәк тә ташларның формалары сокландыра. Ә иң истә калганы – Банан аланына бару. Агачтан яңа гына өзелгән банан, ак груша, хөрмә, әфлисуннан авыз иттек. Тәмнәре, сөбеханалла!

Луксорда булуның өченче көнендә без шәһәр мэры белән күрештек. Ул безгә илнең икътисады турында сөйләде. Безнең белән әңгәмә корды.

Икенче сәяхәт Искәндәр шәһәренә иде. Иң әүвәл элеккеге Рим театрының хәрабәләренә бардык. Аннан соң Урта диңгез буена киттек. Әкиятләрдә дөрес язалар икән: диңгез ачык зәңгәр төстә. Офык сызыгына якынайган саен, төсе дә караңгылана бара. Диңгезнең «кикрикләре» елганыкыннан аерыла. Алар биегрәк тә, ешрак та. Күтәрелеп килеп, ярдагы ташларга бәрелүе була, мең тамчыларга таралып сибелә. Шушы матурлыкка сокланудан, йөрәкне биләп алган шатлыктан күбебез салкынны да сизмәде.

Сәяхәтләр болар белән генә чикләнмәде. Мисырның Гиза районында урнашкан, бар галәмгә билгеле пирамидалар, сфинкс, илнең буеннан буена сузылган Нил елгасы – дәүләтнең визит карточкасы булып тора. Экспонатлар коллекциясе белән данлыклы Каһирә дәүләт музее, кул эшләре фабрикасы, Ислам мәдәнияте музее, папирус ясау фабрикасы, китап ярминкәсе – без булмаган җир калмагандыр.

### Мисырда да Татарстанны беләләр!

Бер кызык хәлне язып үтмичә булмас. Хан әл-хәлил базарына өченче тапкыр барганда, Татарстанны белә торган бер сатучыга юлыктык. Безнең белән сәламләшеп: «Сез кайсы яклардан?» – дип сорады. «Татарстаннан», – дигәч, сатучы безгә: «Сез татарга охшамагансыз. Татарларның күзләре кытайларныкы сыман кысык була. Ә сезнең йөзегез Европа халкына тартым», – диде. Менә сиңа яңалык! Авызыбызны ачтык та калдык.

Шулай көн артыннан көн үтте. Вакытның алга барганы сизелмәде дә. Яңа җиргә күнектек кенә дигәндә, инде кайтыр вакытлар җитте. 23 февраль көнне укытучылар белән саубуллашу кичәсен уздырдык. Алар белән тәмам дусларга әйләнгәнбез икән. Мөгаллимнәр оялып тормады, безгә кушылып моңландылар. Аларга, өйрәнгән гарәп җырлары белән бергә, татар җырын да бүләк иттек. Вакытыбыз юкка үтмәсен дип, төнлә юлга чыгасы көнне дә сәяхәттә – Сәлахетдин бинасында, Мөхәммәт Гали мәчетендә булдык.

Төркем янә аэропортта. Күбесе китәргә теләми. Тагын бер ай булса да Мисырда яшисе килә. Әмма туган якка кайтыр вакыт җитте. Әлеге сәяхәт һәрберебез күңелендә әкияти төш булып калыр. Без – самолётта. Тәгәрмәчләр җирдән аерыла, тимер кошыбыз әкренләп күккә аша. Сау бул, Мисыр, киләсе күрешүләргә кадәр!

● Бөтендөнья метеорология көне

# Караңгы төшүе ихтимал

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Һәр елны 23 март көнне Бөтендөнья метеорология оешмасы инициативасы буенча Метеорология көне уздырыла. Россиядә Гидрометеорологик хезмәткәрләр көне Николай I фәрманы белән 170 елдан артык үткәрелә.

Россия гидрометеорология үзәгенең төп максаты – һава торышын алдан хәбәр итү, климатик күренешләрнең халыкка һәм ил икътисадына китерерлек зыянын киметү, Россиянең гидрометеорологик куркынычсызлыгын булдыру. Анализ нәтиҗәләре күрсәткәнчә, Россия метеорологлары уртача 40% икътисади зыянны булдырмаска ярдәм итә.

Бөтендөнья метеорология көнендә ниндидер бер теманы яктырту күркәм традициягә әверелгән. 2012 елда бу көн «Һава торышы, климат һәм су – киләчәкне хәрәкәтләндерә торган көчләр» девизы астында уза. 2011 елда Бөтендөнья метеорологик конгрессы бертавыштан 2012 елда климатик хезмәт күрсәтүнең глобаль нигезләрен булдыруны кабул итте. Бу, әлбәттә, соңгы елларда кискенләшкән табигый һәлакәтләрне киметергә ярдәм итәчәк. Ә һава торышы, климат һәм су авыл хуҗалыгы, сәламәтлек, транспорт, электр энергиясе кебек социаль-икътисади эшчәнлекне сакларга ярдәм итә.



Белгечләр фикеренчә, әлеге өлкә буенча фәнни эшчәнлекне, тикшеренү-күзәтүләрне яхшырту тормыш иминлеген саклауга иң зур ярдәм булып тора. Казан федераль университеты Экология һәм география институтының метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы бу өлкәгә бик зур өлеш кертә. Биредә инженер-метеорологлар әзерләнә. Белгечләргә Татарстанда гына түгел, хәтта Россия Федерациясе буенча да ихтыяҗ зур. Алар, гадәттә, метеорология оешмаларында, аэропортларда хезмәт күрсәтә.

Метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы доценты Эдуард Наумов сүзләренә караганда, төп мәгълүматны алар Мәскәүдән ала. Ләкин телевидение хезмәткәрләре күбрәк Интернетка таяна һәм тамашачыларга күп кенә ялгыш фикерләр җиткерә. «Бүген кич белән караңгы төшүе ихтимал», мәзәге дә шуңа бәйле тумады микән?!

Ә быелгы яз исә чын-чынлап апрель аенда җитәчәк икән. Безнең белгечләр әйтүенчә, март аенда салкыннар булуы мөмкин. Шулай да һава торышы нормага туры килә. Ә табигый һәлакәтләр турында шунда ук Гадәттән тыш хәлләр министрлыгына хәбәр ителә. Халыкның куркынычсызлыгы өчен алар җавап бирә.

2012 елның 2-5 октябрь көннәрендә Казан федераль университеты базасында Халыкара «Әйләнә-тирә климатик мониторингының региональ үзгәреше» дигән фәнни конференция узачак. Чарага Бөтендөнья метеорология оешмасының генераль секретаре Мишель Жарро да киләчәк.

Соңгы елларда һава торышы темасына бәйле фикер алышулар тагын да актуальләште. Ул безнең кәефкә, сәламәтлеккә дә зур йогынты ясый. Әлеге һөнәр ияләреннән башка безгә яшәве бик авыр булыр иде. Һава торышын, ким дигәндә, бер атна алдан белеп бару алга таба эшләрне планлаштырырга һәм тормышка ашырырга ярдәм итә. Иң мөһиме: халыкның, илнең куркынычсызлыгын тәэмин итү беренче урынга куела.

● Халәт

# Авыл-шәһәр арасы...

**Алсу НУРГАТИНА,**
журналистика һәм социология факультеты студенты



*Балачагы авылда үткән һәр кеше күңеле белән авылга тартылып яши, диләр. Килешмичә булмый. Хәр иртәдә чыклы үләннең исен тоеп, болыннарда чалгы тавышын ишеткән, чишмә буйларыннан сулар ташыган, көзен бакчада мәш килгән баланың күңеле гел авылга тартым була. Шәһәргә китсә дә, ул авылны сагынып яши, күңеленең бер читендә булса да казлар көткән, көтү куган мизгелләр яшеренеп ята. Шәһәрлеләрнең сүзе гади: авылда яшәү рәхәт, сезнең барсы да үзегезнеке. Базардан бәрәңге, кишер җыеп йөрмисез. Ә бит шушы уңыш өчен күпме тырышырга туры килә авыл кешеләренә!*

*Шәһәр халкы авылга тартылып яши дип әйтә алмыйм. Күбесе җылы бәдрәфтән, күнеккән эш урыннарыннан, чиста юллардан коры калырга теләми. Авыл кешесе һәрвакыт эш белән мәшгуль, шәһәрнекеләр дә кимен куймый анысы. Кайбер авыл кызларының да сүзләрен ишеткәлим: авылдан китеп, шәһәрдә яшәргә, дигән максат куялар. Ирексездән тарих укытучыбызның сүзләре искә төшә: «Безнең заманда да кызлар шәһәр дип ашкынды, ләкин шәһәргә атлыкканнары, киресенчә, авылда калдылар...»*

*Авылда туып үскәнгә, аны бик яратам. Бот буе чактан эшкә чумсаң, үсә баргач, эшләгән эш күләме дә, авырлыгы да сизелми. Чишмәләрдән су алып кайтып, көтү каршылап, дөбердәттереп сыер савып керүләрнең рәхәтлекләрен авыл кызы гына беләдер. Бәлки кемгәдер бу көлке тоелыр, тик шушы күңелле мизгелләрне кабатлар өчен, җәй дә зарыктыра.*

*Шәһәр балаларына авыл икеләтә күңелле инде ул. Дәү әниләренә кунакка кайткач, хайваннарның башларыннан сыйпап карау, әтәч кычкырганын тыңлау ләззәтен шәһәргә үз истәлекләрендә алып кайталар. Тәмле бәлеш, өчпочмаклар кафе-рестораннарны бер кырыйга кысрыклап чыгара. Хәзер авыл ашларын да җитештерүчеләре бар, диярсез. Тик авылныкы — авылныкы инде ул! Синең граммлап үлчәнгән бәрәңге, камырыңа тормый! Күмерле мичтә пешкән ризыкларны шәһәрнең «авылчалылыгы» алыштыра алмый.*

*Шәһәрнең дә, авылның да үз өстенлекләре бар. Тик күңел барыбер туган җиргә тарта, аны һәрвакыт сагынып, яратып яши. Минем Казанда авылны яраткан, кайту мизгелләрен зарыгып көтеп яшәүче бер сеңлем бар. Күңеле белән һаман да авылда ул, сирәк кайтсалар да, аны ятатырга өлгерде. Шундыйларның күбрәк булуын телим. Авыллар булганга гына шәһәрләр яши ул!*

● Сәнгать

# Татар мюзиклы

**Гөлнур ДӘҮЛӘТШИНА,**
биология һәм туфракны өйрәнү факультеты студенты





Язгы бер матур көндә Г.Камал исемендәге театрга барырга теләк туды. Илгиз Зәйниевнең «Бәби» пьесасы буенча куелган җырлы-биюле музыкаль тамашага туры килдем.

Менә дигән спектакль булды бу! Бер сулышта үтте. Нинди нәтиҗә ясап була? Кайбер кешеләр мәчеләр һәм этләрдән дә яманрак! Үз балаңны ташлап калдыру – бу нинди гамәл? Кешелеккә хасмы соң әлеге сыйфат?!

Каракүз дигән ана этнең балаларын шәфкатьсез кешеләр атып үтерә. Адәм баласының шундый рәхимсезлегенә хайвани затның гына түгел, укучы-тамашачының йөрәгендә дә нәфрәт уяна. Ана этнең барлык бәндәләргә бик каты ачуы кабара. Йөрәге яраланган булса да, кеше баласының – бәбинең елаганын күреп, чыдый алмый, аны юата башлый, ачыкканын сизеп, үзенең сөтен имезә. Уйлап карагыз әле...

Җәнлекләр бәбине карый, саклый башлыйлар, җырлар җырлап тирбәтәләр, аның намуслы, яхшы күңелле, батыр һәм хайваннарга карата мәрхәмәтле булып үсүенә өметләнәләр. Шул кечкенә генә җан иясе ярдәмендә бер-берсе белән күп еллар буе дошманлашып яшәгән мәчеләр белән этләр дуслаша. Тиздән салкын кыш җитә. Хайваннар баланың мондый кырыс шартларга чыдамаячагын һәм кешеләр арасында үсәргә тиеш булуын аңлый. Нәкъ менә шушы мизгелдә шаян тутый кош – Алехандро, үз хуҗаларының балалар йортыннан бәби алырга теләгәннәрен белеп, ятим калган баланы тизрәк шул кешеләргә илтеп куярга тәкъдим итә.

Соңыннан барысы да Ходайдан бу баланы явызлыклардан саклап калуын сорыйлар. Дөрестән дә, Аллаһы Тәгалә әйткән: «Фәкыйрь булудан куркып, балаларыгызны үтермәгез! Балаларыгызны да, үзегезне дә Без ризыкландырабыз, әлбәттә, үз балаларын үтерүләре гафу ителми торган хатадыр, зур гөнаһдыр».

Дуслар, әгәр бу спектакльгә барсагыз, үкенмәссез, дип уйлыйм. Шәп куелган. Артистлар бик матур уйный, күбесе яшьләр. Ифрат күп җырлар, биюләр белән кушылып бара. Хәтта бу спектакльне күпмедер дәрәҗәдә татар мюзиклы дип атарга да буладыр.

**Белешмәләр өчен: спектакль 15 апрельдә булачак.**

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 999

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: ksu.ru

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.

Газета бушлай таратыла